**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясепоселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 16.12.2020** **№ 942**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итүне оештыру турында**

2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешен гамәлгә ашыру максатларында һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 02 сентябрендәге 458 номерлы «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндә китерелгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча гражданнарны белем алуга кабул итү Тәртибен расларга.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 25 февралендәге 229 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итүне оештыру турында» карарын үз көчен югалткан дип таныргa.
3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе башлыгы Н.К. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

Кушымта
«Расланды»
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 16 декабрендәге
942 нче номерлы
Карары белән

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү**
**ТӘРТИБЕ**

1. Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укырга кабул итү Тәртибе (алга таба - Тәртип) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда Россия Федерациясе гражданнарын башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга кабул итү кагыйдәләрен (алга таба - төп гомуми белем бирү программалары, гомуми белем бирү оешмалары) регламентлаштыра.

2. Федераль бюджетның, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының һәм җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән төп гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү, 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законда (алга таба - Федераль закон) башкасы каралмаган булса, һәркем файдалана алырлык нигездә уздырыла.

3. Чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны, шул исәптән чит илдә яшәүче ватандашларны федераль бюджетның, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының һәм җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән төп гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү Россия Федерациясенең халыкара килешүләре, Федераль закон һәм әлеге Тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Төп гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү кагыйдәләре, әгәр Федераль законда башкасы каралмаган булса, тиешле дәрәҗәдәге гомуми белем алырга хокуклы барлык гражданнарны кабул итүне тәэмин итәргә тиеш.

5. Муниципаль берәмлек оешмаларын муниципаль районның конкрет территорияләренә беркетү, муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан мәгариф өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча гамәлгә ашырыла.

6. Муниципаль мәгариф оешмалары үзләренең мәгълүмат стендында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба - Интернет челтәре) муниципаль районның җирле үзидарә органының агымдагы елның 15 мартыннан да соңга калмыйча нәшер ителә торган мәгариф оешмаларын муниципаль районның (шәһәр округының) яисә Россия Федерациясе субъектының

конкрет территорияләренә беркетү турында тиешле күрсәтмә актын ул басылып чыккан вакыттан алып 10 календарь көн эчендә урнаштыралар.

7. Мәгариф турындагы законнар белән җайга салынмаган өлештә төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга конкрет гомуми белем бирү оешмасына кабул итү кагыйдәләре гомуми белем бирү оешмасы тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.

Гомуми белем бирү оешмасының филиалына укырга кабул итү гомуми белем бирү оешмасында укырга кабул итү кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

8. Гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алу сәламәтлеге торышы буенча каршылыклар булмаганда, балаларга алты яшь һәм алты ай тулу белән башлана, әмма алар сигез яшь тулганнан соңга калмыйча. Гомуми белем бирү оешмасын гамәлгә куючы балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) гаризасы буенча балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга иртә яисә соңрак укырга рөхсәт итәргә хокуклы.

9. Чираттан тыш тәртиптә интернаты булган гомуми белем бирү оешмаларында урыннар бирелә:

«Россия Федерациясе прокуратурасы турында» 1992 елның 17 гыйнварындагы 2202-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 44 статьясының 5 пунктында күрсәтелгән балаларга;

«Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» 1992 елның 26 июнендәге 3132-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 19 статьясының 3 пунктында күрсәтелгән балаларга;

«Россия Федерациясе Тикшерү комитеты турында» 2010 елның 28 декабрендәге 403-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясының 25 өлешендә күрсәтелгән балаларга.

10. Беренче чиратта «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 6 өлешенең икенче абзацында күрсәтелгән балаларга аларның гаиләләренең яшәү урыны буенча дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында урыннар бирелә.

Беренче чиратта шулай ук «Полиция турында» 2011 елның 7 февралендәге 3-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән балаларга, эчке эшләр органнарының полиция хезмәткәре булмаган хезмәткәрләренә һәм «Башкарма хакимиятнең кайбер федераль органнары хезмәткәрләренә социаль гарантияләр һәм Россия Федерациясе закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 30 декабрендәге 283-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 14 өлешендә күрсәтелгән балаларга яшәү урыны буенча милек формасына бәйсез рәвештә гомуми белем бирү оешмаларында урыннар бирелә.

11. Гомуми белем бирү оешмасына укырга кабул итү, укытуга кабул ителгәндә махсус хокуклар (өстенлекләр) бирелгән затлардан тыш, барлык керүчеләр өчен дә кабул итүнең тигез шартлары принципларында уздырыла.

12. Бер гаиләдә яшәүче һәм яшәү урыны уртак булган балалар абыйлары (яисә) апалары белем алган башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча белем алуга өстенлекле кабул итү хокукына ия.

13. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең җайлаштырылган белем бирү программасы буенча

(алга таба - җайлаштырылган белем бирү программасы) һәм бары тик аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән һәм психологик-медик-педагогик комиссия киңәшләре нигезендә генә кабул ителә.

14. Гомуми белем бирү оешмасына керү буш урыннар булганда бөтен уку елы дәвамында гамәлгә ашырыла.

15. Муниципаль мәгариф оешмасына кабул итүдә, Федераль законның 67 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләрендә һәм 88 статьясында каралган очраклардан тыш, анда буш урыннар булмау сәбәпле генә кире кагылырга мөмкин. Дәүләт яисә муниципаль белем бирү оешмасында урыннар булмаган очракта, баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) аны башка гомуми белем бирү оешмасына урнаштыру мәсьәләсен хәл итү өчен турыдан-туры Россия Федерациясе субъектының мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы башкарма хакимияте органына яисә мәгариф өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органына мөрәҗәгать итә.

16. Муниципаль белем бирү оешмалары, балаларны оешкан төстә беренче сыйныфка кабул итү максатында, үзләренең мәгълүмат стендында һәм Интернет челтәрендәге рәсми сайтта түбәндәге мәгълүматны урнаштыралар:

беренче сыйныфларда урыннар саны турында, Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән күрсәтмә акты басылып чыкканнан соң, 10 календарь көннән дә соңга калмыйча;

беркетелгән территориядә яшәмәүче балаларны кабул итү өчен беренче сыйныфларда буш урыннар булу турында агымдагы елның 5 июленнән дә соңга калмыйча.

17. Тәртипнең 9, 10 һәм 12 пунктларында, шулай ук беркетелгән территориядә яшәүче балалар өчен беренче сыйныфка укырга керү турында гаризалар кабул итү агымдагы елның 1 апрелендә башлана һәм бу елның 30 июнендә тәмамлана.

Гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән балаларны укытуга кабул итү турында беренче сыйныфка кабул итү турында гаризаларны кабул итү тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә күрсәтмә акт чыгара.

Беркетелгән территориядә яшәмәгән балалар өчен беренче сыйныфка укырга алу турында гаризалар кабул итү агымдагы елның 6 июлендә, буш урыннарны тутырганчы, ләкин агымдагы елның 5 сентябреннән дә соңга калмыйча башлана.

Тәртипнең 9, 10 һәм 12 пунктларында күрсәтелгән, шулай ук беркетелгән территориядә яшәүче барлык балаларны беренче сыйныфка кабул итеп бетергән муниципаль белем бирү оешмалары беркетелгән территориядә яшәмәгән балаларны бу елның 6 июленнән дә иртәрәк кабул итә.

18. Аерым уку предметларын тирәнтен өйрәнү белән яисә профильле укыту өчен төп гомуми һәм урта гомуми белем алу өчен муниципаль мәгариф оешмаларына кабул ителгәндә индивидуаль сайлап алуны оештыру Россия Федерациясе субъекты законнарында каралган очракларда һәм тәртиптә рөхсәт ителә.

19. Төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында физик культура һәм спорт өлкәсендә өстәмә һөнәралды белем бирү программалары белән интеграцияләнгән, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү уку-укыту программалары белән интеграцияләнгән яисә сәнгать өлкәсендә урта

һөнәри белем бирү программалары төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары белән интеграцияләнгәнбелем бирү оешмаларында белем алуга гражданнарны кабул иткәндә конкурс яисә индивидуаль сайлап алу оештыру, сәнгать яисә спортның аерым төре белән шөгыльләнүгә сәләтләрне бәяләү нигезендә, шулай ук тиешле спорт төре белән шөгыльләнүгә каршылыклар булмаганда гамәлгә ашырыла.

20. Белем алуга кабул иткәндә, гомуми белем бирү оешмасы укырга керүчене һәм аның ата-анасын (законлы вәкилләрен) үз уставы, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе, дәүләт аккредитациясе турында таныклыгы, белем бирү эшчәнлеген оештыруны һәм гамәлгә ашыруны регламентлаштыра торган гомуми белем бирү программалары һәм башка документлар, белем алучыларның хокуклары һәм бурычлары белән таныштырырга бурычлы.

21. Башлангыч гомуми һәм төп гомуми белем бирүнең дәүләт аккредитациясе булган белем бирү программалары буенча укырга кабул ителгәндә, Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан туган телне, шул исәптән туган тел буларак рус телен, Россия Федерациясе республикаларының дәүләт телләрен сайлап алу балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) гаризасы буенча гамәлгә ашырыла.

22. Төп гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү баланың ата-анасының (законлы вәкиленең) яисә Федераль законның 34 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган хокукны гамәлгә ашыручы укырга керүченең шәхси гаризасы буенча гамәлгә ашырыла.

23. Тәртипнең 26 пунктында күрсәтелгән укырга кабул итү турында гариза һәм укырга кабул итү өчен документлар түбәндәге ысулларның берсе тарафыннан бирелә:

шәхсән гомуми белем бирү оешмасына;

заказлы хатта гомуми файдаланудагы почта элемтәсе операторлары аша тапшырылу турында хәбәрнамә белән;

электрон рәвештә (кәгазь документ формасында, электрон формага, машинада укыла торган реквизитларын тануны тәэмин итеп сканлау яки фотога төшерү юлы белән белән үзгәртелгән ) гомуми белем бирү оешмасының яисә гомуми белем бирү оешмасының электрон мәгълүмат системасының электрон почтасы ярдәмендә, шул исәптән Интернет челтәрендә гомуми белем бирү оешмасының рәсми сайты функционалыннан файдаланып яисә Интернет челтәрен кулланып башка ысул белән;

Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан төзелгән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт мәгълүмат системалары булган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталлары функционалыннан (сервисларыннан) (булган очракта) файдаланып.

Гомуми белем бирү оешмасы укуга кабул итү турындагы гаризада күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеген һәм тапшырылган электрон документларның чынлыкка туры килүен тикшерә. Күрсәтелгән тикшерүне уздырганда гомуми белем бирү оешмасы тиешле дәүләт мәгълүмат системаларына, дәүләт (муниципаль) органнарына һәм оешмаларга мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

24. Баланың  атасының йә анасының (законлы вәкиленең) яисә Федераль законның 34 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган хокукны гамәлгә ашыручы укырга керүченең укытуга кабул итү турындагы гаризасында түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

баланың яисә укырга керүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);
баланың яисә укырга керүченең туу датасы;
баланың яисә укырга керүченең яшәү урыны адресы һәм (яисә) тору урынының адресы;
баланың ата-анасының(законлы вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);
баланың ата-анасының (законлы вәкиленең) яшәү урынының адресы һәм (яисә) тору урынының адресы;
баланың яисә укырга керүченең ата-анасының (законлы вәкиленең) электрон почтасы адресы (лары), телефон номеры (лары);
чираттан тыш, беренче чиратта яисә өстенлекле кабул итү хокукы булу турында;
«баланың яисә укырга керүченең адаптацияләнгән белем бирү программасы буенча укытуда һәм (яисә) сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучыны индивидуаль реабилитация программасы нигезендә психолог-медик-педагогик комиссия бәяләмәсе нигезендә (булган очракта) яисә инвалид (инвалид бала) булганда индивидуаль реабилитация программасы нигезендә укыту һәм тәрбияләүне оештыру өчен махсус шартлар тудыруга ихтыяҗы турында;
баланың адаптацияләнгән белем бирү программасы буенча баланы укытуга ата-анасының (законлы) вәкиленең) ризалыгы (баланы җайлаштырылган укыту программасы буенча укыту кирәк булган очракта);
белем бирү теле (Россия Федерациясе халыклары телләреннән берсендә туган телдә белем алган очракта яисә чит телдә);
Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан туган тел (Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан туган телне, шул исәптән туган тел буларак рус телен өйрәнүгә хокукны гамәлгә ашырган очракта);
Россия Федерациясе республикасы дәүләт теле (гомумбелем бирү оешмасы тарафыннан Россия Федерациясе республикасы дәүләт телен өйрәнү мөмкинлеге бирелгән очракта);
баланың ата-анасын (законлы вәкилен(ләрен)) яисә укырга керүчене устав белән, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия, дәүләт аккредитациясе турында таныклык, белем бирү эшчәнлеген оештыруны һәм гамәлгә ашыруны регламентлаштыра торган гомуми белем бирү программалары һәм башка документлар, белем алучыларның хокуклары һәм бурычлары белән таныштыру факты;
баланың ата-анасының (законлы вәкил(ләр)енең) яисәукырга керүченең шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы.
25. Белем алуга кабул итү турында гариза үрнәге гомуми белем бирү оешмасы тарафыннан үзенең мәгълүмат стендында һәм Интернет челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.
26. Баланың ата-анасы (законлы вәкил(ләр)е) яисә укырга керүче түбәндәге документларны тапшыра:
баланың атасының яисә анасының (законлы вәкиленең) яисә укырга керүченең шәхесен раслаучы документның күчермәсен;

бала туу турында таныклык яисә мөрәҗәгать итүченең туганлыгын раслый торган документ күчермәсен;

опека яисә попечительлек (кирәк булганда) билгеләүне раслый торган документның күчермәсен;

баланы яки укырга керүчене беркетелгән территориядә яшәү урыны яисә булу урыны буенча теркәү турындагы документның яисә яшәү урыны буенча теркәлүне рәсмиләштерү өчен документларны кабул итү турындагы белешмәнең (беркетелгән территориядә яшәүче баланы яисә укырга керүчене кабул иткәндә яисә башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укытуга өстенлекле кабул итү хокукы кулланылган очракта) күчермәсен;

баланың ата-анасының (законлы вәкил(ләр)енең) эш урыныннан (укытуга чираттан тыш яисә беренче чиратта кабул итү хокукы булганда) белешмә;

психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсенең күчермәсен (булган очракта).

Гомуми белем бирү оешмасына килгәндә һәм (яисә) гомуми белем бирү оешмасының вәкаләтле вазыйфаи затлары белән үзара хезмәттәшлек иткәндә баланың ата-анасы (законлы вәкил(ләр)е) әлеге пунктның 2 - 5 абзацларында күрсәтелгән документларның төп нөсхәләрен, ә укырга керүче шәхесне таныклау документының оригиналын күрсәтә.

Урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул ителгәндә билгеләнгән тәртиптә бирелгән төп гомуми белем турында аттестат тапшырыла.

Чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат булган баланың ата-анасы (законлы вәкил(ләр)е) өстәмә рәвештә гариза бирүче(ләр)нең туганлыгын (яисә бала хокукларын күрсәтүнең законлылыгын) раслый торган документ һәм баланың Россия Федерациясендә булу хокукын раслый торган документ күрсәтә.

Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар барлык документларны рус телендә яисә билгеләнгән тәртиптә расланган рус теленә тәрҗемә белән бергә бирәләр..

27. Төп гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итүгә нигез буларак башка документларны тапшыруны таләп итү рөхсәт ителми.

28. Баланың ата-анасы (законлы вәкил(ләр)е) яисә укырга керүче үз теләге белән башка документлар тапшырырга хокуклы

29. Укырга кабул итү турында гаризаны кабул итү факты һәм баланың ата-анасы (законлы вәкил(ләр)е) яисә укырга керүче тапшырган документлар исемлеге гомуми белем бирү оешмасына укырга кабул итү турында гаризалар кабул итү журналында теркәлә. Баланың ата-анасы (законлы вәкил(ләр)е) яисә укырга керүчетапшырган укырга кабул итү турында гариза һәм документлар исемлеге теркәлгәннән соң, баланың ата-анасына (законлы вәкил(ләр)енә) яисә укырга керүчегә укырга кабул итү турында гаризаның һәм укырга кабул иткәндә тапшырылган документлар исемлегенең индивидуаль номерын үз эченә алган, укырга кабул итеп алу турында гаризаларны һәм документларны кабул итүгә җаваплы гомуми белем бирү оешмасының вазыйфаи заты имзасы белән таныкланган документ бирелә.

30. Гомуми белем бирү оешмасы шәхси мәгълүматлар өлкәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә гомумбелем бирү оешмасына керүче

персональ мәгълүматларны кабул итүгә бәйле рәвештә алынган мәгълүматларны эшкәртә.

31. Гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе, Тәртипнең 17 пунктында каралган очрактан тыш, укырга кабул итү турында гариза һәм тапшырылган документлар кабул ителгәннән соң 5 эш көне эчендә баланы яки укырга керүчене укырга кабул итү турында күрсәтмә акт чыгара.

32. Гомуми белем бирү оешмасына кабул ителгән һәр балага яисә керүчегә баланың ата-анасы(законлы вәкил(ләр)е) яисә укырга керүче тапшырган укырга кабул итү турында гариза һәм барлык документлар (документларның күчермәләре) саклана торган шәхси эш формалаштырыла.